# КАРАР

**“14” ноябрь 2019 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 14 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту иту буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру Матросов урамы 1шт, Яшел урамы 1шт,
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру Яңа урамы, Яшел урамы,
- Иске Чүриле авылы зиратының арткы өлешен койма белән әйләндереп алу,
- Яңа урам буенча балалар мәйданчыгын төзү,
- Яшел урамы буенча чокырны төзекләндерү,
- юл-урам челтәрен вак таш-грунт катламы белән каплау Яшел урамы – 500м, Яңа урамы-300м, Матросов урамы-300м;

« ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 564 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 283 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 274 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 9 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә Иске Чүриле авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру Матросов урамы 1шт, Яшел урамы 1шт,

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру Яңа урамы, Яшел урамы,

- Иске Чүриле авылы зиратының арткы өлешен койма белән әйләндереп алу,

- Яңа урам буенча балалар мәйданчыгын төзү,

- Яшел урамы буенча чокырны төзекләндерү,

- юл-урам челтәрен вак таш-грунт катламы белән каплау Яшел урамы – 500м, Яңа урамы-300м, Матросов урамы-300м;

ӘЙЕ» - 274 “КАРШЫ“-9

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Хидиятуллин